# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**12 ноябрь 2025 ел** **№ 2**

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда 1төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан тыш, Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 (җиде йөз) сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 350 (өч йөз илле) сумга киметеп, үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (энергияне саклый торган лампалар, электр товарлары, махсус җайланмалар һәм башка материаллар сатып алу һәм урнаштыру, яктырткычларны һәм урам яктырткычларын алмаштыру, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү);
- **торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (Ә.Вәлиев урамындагы 23нче йорттан алып - 27нче йортка; 41/2 нче йорттан алып – 47А йортына кадәр юлга вак таш сатып алу, төяү, ташу, тарату, юлны профильләштерү);
- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге башлыгы Р.К.Галимҗанова